**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Төрнәс авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2 нче май 2023 нче ел** **№ 52**

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

59 нчы статьяның 3 нче пункты нигезендә “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 06 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Төрнәс авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советы,

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсе дә мираска хокуклы булмаса, яисә барлык варислар мирастан баш тартсалар һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын әйтмәсә;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч еллык срок узу;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. «Җирле салымнар буенча бурычлар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнаяс авыл җирлеге Советының 2021 нче елның 28 нче апрелендәге 17 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге Советы рәисе С.В. Белов